ГЛАВА
Салаушского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Салагыш авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

18.10.2019 Салагыш авылы № 6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Татар Чилчәсе авылында халыкның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» 2004 нче елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге башлыгы
к а р а р б и р д е:

1. 2019 нчы елның 31 октябренә Татар Чилчәсе авылының элеккеге мәктәп бинасында халыкның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын 09 сәгатькә билгеләргә.

2. Халык җыенына кертелә торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Салагыщ авыл җирлегенең Татар Чилчәсе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән шулай ук даими рәвештә бер елдан артык яшәүче, балигъ булган һәр халыкка 2020 нче елда үзара салымны 350 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Татар Чилчәсе һәм Ямурза авылы арасындагы юлга вак таш сатып алу һәм чокырларны ямау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе
Авыл җирлеге башлыгы М. М. Мөхәммәдиев

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Салагушского сельского поселения
Салагыш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002491
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ